**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422610 г.Лаишево,**
**ул. Первомайская, д.39**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ район СОВЕТЫ**

**422610 Лаеш ш.,**
**Беренче май урамы, 39 нчы йорт,**
**тел: (8-84378) 2-51-51**
**факс: (8-84378) 2-55-55**

---

**2024елның 7 марты** **21-РС номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм инвалидлары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»2018 елның 16 февралендәге 5-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексы,"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Җир кодексы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы белән 2020 елның 22 сентябрендәге 34-557/2020 номерлы эш буенча Татарстан Республикасы Югары суды карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә теркәлгән инвалидларга һәм үз составында инвалидлар булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы, КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә инвалидларга һәм инвалидлары булган гаиләләргә җир кишәрлекләрен беренче чиратта бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» (алга таба –Нигезләмә) 2018 елның 16 февралендәге 5-РС номерлы Лаеш муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1 2.1 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлдәге закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә даими яшәүче Инвалид».

1.2 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы торак пункты чикләрендә инвалидларга даими яшәү урыны буенча беренче чиратта җир кишәрлекләре бирелә».

1.3 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җир кишәрлекләрен беренче чиратта сатып алырга теләүче инвалидлар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына гариза белән мөрәҗәгать итәләр. Гаризага түбәндәге документлар кушылырга тиеш:

- дәүләт медицина-социаль экспертиза хезмәте учреждениесе тарафыннан бирелгән инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә (күчермә, чагыштыру өчен оригинал);

- паспортның барлык битләре (күчермә, тикшерү өчен оригинал).

Җир кишәрлеген беренче чиратта арендага бирү турындагы гаризада соралган җир кишәрлеге турында тулы мәгълүмат күрсәтелә, атап әйткәндә: урыны, мәйданы, рөхсәт ителгән куллану төре, җир кишәрлеге категориясе.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

4. Әлеге карар кабул ителгәннән соң үз көченә керә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**